**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карары**

Азнакай шәһәре №386-55 2015 елның «25» августы

Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Азнакай район Советының 2015 елның 19 мартындагы 347-51 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе

Азнакай район Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай шәһәр Советына әлеге карарны алган көннән алып 30 көн эчендә Азнакай муниципаль районы башкарма комитетына гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы берләшмәләргә ярдәм күрсәтү буенча Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай шәһәр Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәрне кабул иткән очракта, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетына Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтне тапшыру турында килешү төзергә тәкъдим итәргә, төзелә торган килешүнең гамәлдә булу 2015 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дигән карарга.

3. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль

районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http/aznakayevo. tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай район Советының Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин